Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты

*А.М. Гайнетдинов*

# МӘРҖАНИ БЕЛӘН БӘЙЛЕ ЭПИГРАФИК ИСТӘЛЕКЛӘР

Казан – 2018

УДК 930.27:94(470.41)
ББК 63.2(2Рос.Тат)+ 63.3(2Рос.Тат)
Г 14

**Фәнни мөхәррир:**
ТР ФА академигы, тарих фәннәре докторы *Р.Р. Салихов*

**Рецензентлар:**
филология фәннәре докторы *М.И. Әхмәтҗанов*
тарих фәннәре кандидаты *А.И. Ногманов*

***Гайнетдинов А.М.***
Г 14 **Мәрҗани белән бәйле эпиграфик истәлекләр**. – Казан: ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2018. – 72 б.

ISBN 978-5-94981-291-4

Китапта күренекле галимебез Ш. Мәрҗани белән бәйле гарәп язулы эпиграфик истәлекләрнең текстлары, аларның хәзерге телгә күчермәләре, фотолары китерелде. Әлеге ташбилгеләр галимебез һәм аның туганнары каберләренә куелганнар, хәзерге көнгә кадәр сакланып калганнар.

Хезмәт тарихи-мәдәни мирасыбызны өйрәнүче галимнәргә, мөгаллимнәргә, аспирантларга, гомумән, татар халкы тарихы белән кызыксынучы укучыларга тәкъдим ителә.

ISBN 978-5-94981-291-4 УДК 930.27:94(470.41)
ББК 63.2(2Рос.Тат)+ 63.3(2Рос.Тат)

© Гайнетдинов А.М., 2018
© ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, 2018

# ШИҺАБЕТДИН ХӘЗРӘТ ҺӘМ КАБЕР ТАШЛАРЫ

Күренекле татар галиме Шиһабетдин Мәрҗани (1818–1889) шактый күп фән өлкәләрен яхшы белгән, шул исәптән эпиграфика тармагында да үзен чын белгеч буларак танытткан. Ул кечкенәдән үк эпиграфик истәлекләр белән кызыксына башлаган: әле үсмер чагында ук авылыннан ерак түгел бер җирдә урнашкан кабер ташларының текстларын укып кайткан булган[1]. Мәрҗани байтак борынгы кабер ташларын ачыклаган һәм үзенең мәшһүр «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» исемле хезмәтендә аларның тулы текстларын теркәп калдырган. Кызганычка каршы, галим тапкан эпиграфик материалларның байтак өлеше бүгенге көнгә хәтле сакланып калмаган.

Галимебез Ш. Мәрҗанинең ташбилгеләргә карата мөнәсәбәтен белү өчен, иң беренче чиратта, үзенең әйтеп калдырган васыятьләренә игътибарыбызны юнәлтик. Мәрҗани үләренә өч ай кала, ягъни 1889 елның 25 гыйнварында үзенең шәкерте мулла Гобәйдуллага хат белән түбәндәге васыятен язган: «Үлсәм, каберемә бер таш яздырып куй. Бик кечкенә, бер-ике кеше генә күтәреп китәрлек булмасын. Һәм рус сүзе, рус елы куелмасын»[2]. Димәк, Ш. Мәрҗани кабер өстенә таш куюга карата уңай караган һәм шәригатьтә моны тыючы дәлилләр тапмаган.

Хәзерге дин әһелләре борынгы кабер ташларын өйрәнү белән артык кызыксынмыйлар, дияргә мөмкин, чөнки

[1] Шәрәф Ш. Мәрҗанинең тәрҗемәи хәле / Ш. Шәрәф // Мәрҗани: Шиһабеддин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең вәлядәтенә йөз ел тулу (1233–1333) мөнәсәбәтилә нәшер ителде. – Казан: «Мәгариф» матбагасы: Нашире Салих бине Сабит Гобәйдуллин, 1333 (1915). – Б. 25.

[2] Шунда ук. – Б. 191.

имамнар өчен тәкъдим ителә торган махсус Нигезләмәдә түбәндәге сүзләр язылган: «Үзеңнең берәр туганыңны эзләү максаты белән каберләр арасында йөрергә мөмкин, ләкин бары тик кабер ташларын уку өчен генә каберләр арасында йөрү хупланмый»[3]. Дин башлыклары кабер ташының үлчәменә дә чик куялар: «Кабер ташының уртача биеклеге – җирлекнең уртача кар катлавының иң өске ноктасыннан – илле сантиметрдан да артык булырга тиеш түгел (Татарстан өчен кабер ташының биеклеге сиксән биш сантиметрдан туксан сантиметрга кадәр булырга мөмкин)»[4]. Ш. Мәрҗани исә ташның зурысын да, кечесен дә куюда бернинди начарлык күрмәгән, чөнки үзенең каберенә ике кеше күтәрә алмаслык дәрәҗәдәге зур таш куюларын сораган. Димәк, имам-хатыйблар өчен гыйбадәт кылулар һәм дини йолалар уздыру турындагы Нигезләмәне төзегәндә, олуг дин галиме Ш. Мәрҗанинең фикерләрен исәпкә алмаганнар.

Шулай ук бүгенге хәзрәтләребез белән Ш. Мәрҗани арасында мәет белән бәйле кайбер дини йолалар хакында да каршылыклар бар. Вафатына бер атна калгач, Ш. Мәрҗани Садыйк Галикәевне чакыртып, түбәндәге сүзләр әйткән: «Гүр сәдакалары бирү һәм өч, җиденче көннәрдә аш булмас, кирәк нәрсәләр түгел. Фидия бирмәссез, үткәрмәссез. Иншалла, калган рузам, калган намазым булмас»[5]. Бу васыятендә галимнең халыкта таралган кайбер йола-

---

[3] Гыйбадәт кылулар һәм дини йолалар уздыру турында Нигезләмә. – Казан: Хузур, 1436/2014. – Б. 40.

[4] Шунда ук. – Б. 38.

[5] Төрле язмалар // Мәрҗани: Шиһабеддин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең вәлядәтенә йөз ел тулу (1233–1333) мөнәсәбәтилә нәшер ителде. – Казан: «Мәгариф» матбагасы: Нашире Салих бине Сабит Гобәйдуллин, 1333 (1915). – Б. 607; Төрле язмалар // Мәрҗани: фәнни-популяр җыентык. – Казан: Җыен, 2010. – Б. 654.

ларга карата мөнәсәбәтен күреп була. Димәк, Мәрҗани мәет өчен уздырыла торган өчесе, җидесе кебек мәҗлесләргә каршы булган һәм аларны шәригатькә каршы килә торган эшләр дип санаган. Моңа шулай ук аның «Әлбәркыль-вәмидъ» дигән хезмәте дәлил була ала. Анда түбәндәгечә язылган: «Сәдака бирү дөрес дигән гомуми кагыйдә белән гүр сәдакасын, үлгәннән соң өченче, җиденче көннәрдә мәҗлесләргә чакыруларны һәм моныңише эшләрне шәригатькә туры килә дип санарга ярамый»[6].

Ш. Мәрҗани гүр сәдакасын бирүне дә дөрес дип санамаган, әмма үзе аны, бирсәләр, бүләк формасында кабул иткән. Моны ул болай аңлаткан: «Гүр сәдакасы һәм аңа җанлы мал бирү шәргый бер нәрсә түгел, карт хәзрәтләрдән калган бер бүләк, без аны шулай дип алабыз»[7].

Мәет вафат булганнан соң уздырыла торган кайбер дини мәрасимнәргә олуг галимебез Ризаэтдин Фәхретдин дә каршы булган, бу мәҗлесләрне арттыру, адашу һәм зур ялгышу дип санаган һәм гөнаһлы гамәлләр рәтенә куйган[8]. Ул «Җәвамигыль-кәлим шәрехе» хезмәтендә: «…Кабер сәдакасын, мәет җирләүнең беренче, өченче һәм җиденче, кырыгынчы һәм ел тулу көннәренә хаслап кунак итүне, мәетләр өсләрендә тәһлил әйтүләр, махсус көннәрдә һәм махсус рәвешләрдә җыелышып, мәгълүм саннар белән укуларны шәригать гыйбадәтләреннән санарга мөмкин түгел»,

---

[6] Мәрҗани Ш. Әл-бәркыйль-вәмидъ галәл-бәгыйдыйль-мөсәмма бин-нәкыйдъ / Ш. Мәрҗани. – Казан: Вячеслав типографиясе, 1888. – Б. 63.

[7] Төрле язмалар // Мәрҗани: фәнни-популяр җыентык. – Казан: Җыен, 2010. – Б. 657.

[8] Фәхреддин Р. Җәвамигыль-кәлим шәрехе / Р. Фәхреддин.- Оренбург, 1916. – Б. 163.

– дип язган[9]. Шунысы кызыклы: Р. Фәхретдин бу сүзләрен һәм карашларын Ш. Мәрҗанинең «Әл-бәркыль-вәмидъ» дигән хезмәтеннән алган һәм кайбер җөмләләрне шуннан сүзен сүзгә диярлек «Җәвамигыль-кәлим шәрехе» китабына күчереп язган. Ул бу турыда үзе дә әйткән: «Бу хәдис шәрехендә булган сүзләрнең күбесе «Сахих Бохари», «Сахих Мөслим» шәрехләреннән, «Минһаҗес-сөннә», «Фәтәва Ибне Тәймия», «Әл-бәркыйль-вәмидъ» китапларынан, шулай ук «Әл-мәнар» журналыннан алынды»[10].

Галим Урта Азия суфиларының каберләрне артык олылауларын, мәетләрдән ярдәм сорауларын нык яратмаган. Бу турыда Ш. Шәрәф түбәндәгечә язган: «Бохараның дәрес тәртипләрен һәм байтак кагыйдәләрен яратмады. Бохара халкының каберләрен артык олылауларына, мәетләрдән ярдәм-булышлык сорауларына бик эче поша иде. Бервакыт янгын булганда, шундагы халыкның: Йа, Хуҗа Баһаведдин, ярдәм ит», – дип кычкырып торуларын күреп: «Безнең авыл халкы болардан байтак югары. Ярдәмне Аллаһтан сорыйлар. Тәкбир һәм азан әйтәләр», – дияргә теләгән иде[11].

Гомумән, безнең атаклы дин галимнәребез кабер ияләрен изгеләштереп, алардан нәрсәдер сорау, ялвару, бәрәкәт эзләү, каберләре янында корбаннар чалу, табыну урыны ясауларны гөнаһлы гамәлләр дип санаганнар. Мәсәлән, Галимҗан Баруди болай дип язган: «Нәтиҗә: зияраттән беренче максат – үлемне искә төшерү, моның белән үзеңне төзәтеп, ахирәткә әзерләнү. Үлемне бервакытта да истән чыгару дөрес булмаса да, дөнья шөгыль-

---

[9] Шунда ук. – Б. 443.

[10] Шунда ук. – Б. 443.

[11] Шәрәф Ш. Мәрҗанинең тәрҗемәи хәле / Ш. Шәрәф // Мәрҗани: фәнни-популяр җыентык. – Казан: Җыен, 2010. – Б. 85.

ләре сәбәпле, күбесенчә үлемнән гафләт ителә. Каберләргә зиярәт исә бу гафләт китүгә, үлем искә төшүгә сәбәп була. Сөннәт булган зиярәт – бу рәвештәге зиярәт. Башка рәвештәге зиярәт, мәсәлән, «әүлия каберләре» дип билгеле булган каберләргә сәдакалар бирү (Шәһри Болгар һәм Хуҗалар тавы ише зиратларына барып, корбаннар чалу кебек), корбаннар чалу, алардан ярдәм сорау, хаҗәтләр сорау – мондый зиярәтләр сөннәткә каршы, бәлки кабәхәт бидгать һәм бер төр мәҗүсилек»[12]. Шулай ук иң олуг дин галимнәребезнең берсе Ризаэддин Фәхреддиннең түбәндәге сүзләрен китерергә мөмкин: «Каберләрдән һәм шәехләрдән ярдәм сорау гадәте әүвәлге мөселманнарда юк иде. Ислам дөньясына моны надан суфилар чыгардылар, халыклар арасына яхшы бер эш итеп күрсәттеләр»[13]. Димәк, ул каберләрне чамадан тыш олылауны суфичылыктан күргән.

Соңгы елларда суфичылыкка мөкиббән китүче кайбер тарихчылар Шиһабетдин хәзрәтне суфи булган дип күрсәтергә тырышалар, янәсе, аның остазлары ишан булган һ.б. Дөрес, ул Бохара һәм Сәмәрканд шәһәрләрендә ишан остазларда укыган, әмма Ш. Мәрҗани, китапханәләрдә көнтөн утырып, гыйлемне үзлегеннән китаплардан үзләштергән, Урта Азия галимнәренә аның күңеле ятмаган, чөнки анда бирелгән гыйлем, схоластикага, тәкълидкә нигезләнгәнлектән, аны канәгатьләндермәгән, шуңа күрә остазлары артыннан китмәгән, башка юл сайлаган, гамәли суфичылыктан ерак торган, хәтта ишаннарны тәнкыйтьләгән. Галимнең замандашлары, шәкертләре әйтеп кал-

---

[12] Баруди Г. Хәдис: Гыйлемсез галим, төш мәсьәләсе, зиярәте кобур хәдисе. Хатыннарның кабергә зиярәтләре. Әдәбе зиярәт / Г. Баруди // Дин вә әдәб. – 1913. – № 24. – Б. 743.

[13] Фәхреддин Р. Җәвамигыль-кәлим шәрехе / Р. Фәхреддин. – Оренбург, 1916. – Б. 368.

дырганча, аның бөтенләй мөридләре булмаган, «ишан» сүзеннән көлгән, вирдләр урынына фәкать Коръән генә укыган[14], шулай ук үзенең бер хезмәтендә суфиларның билгеле бер вакытта билгеле бер микъдарда билгеле бер зикерләр әйтүләрен шәригать буенча дөрес булмавын язып калдырган[15]. Өстәвенә, Ш. Мәрҗани көндәлек тормышында аскет булмаган: затлы киемнәр кигән, күп ашаган, яхшы атларга утырып йөргән, зур йортта торган, шактый бай тормыш белән яшәгән. Кайбер хезмәтләрендә суфичылыкка карата уңай карашын белдерсә дә, ул фәлсәфи суфичылыкны, ягъни рухи камиллекне, аскетизмны күздә тоткан, ә аның гамәли юнәлешен сөймәгән. Бервакыт берәү бер ишанга барып, мөрид булып, шуңа хезмәт итәргә Мәрҗанидән рөхсәт сорагач, галим: «Юк эш белән йөри күрмә», – дигән[16]. Икенче берәү, тарикатькә керергә теләп, галимнән камил мөршид дәрәҗәсендә булган берәр кешене күрсәтүен үтенгәч, Мәрҗани аңа: «Иң яхшы мөршид – Коръән», – дип җавап биргән[17]. Әгәр дә Ш. Мәрҗани суфи булса, Г. Тукай аны нык мактап шигырь язмас, киресенчә, тәнкыйтьләп чыккан булыр иде, чөнки бөек шагыйребез

[14] Гомәри Г. Бөек остаз Мәрҗани хәзрәте хакындагы хатирәм / Г. Гомәри // Мәрҗани: фәнни-популяр җыентык. – Казан: Җыен, 2010. – Б. 525–526.

[15] Мәрҗани Ш. Әл-бәркыйль-вәмидъ галәл-бәгыйдыйль-мөсәмма бин-нәкыйдъ / Ш. Мәрҗани. – Казан: Вячеслав типографиясе, 1888. – Б. 63.

[16] Мәрҗани (Русия мөселманнарының бөек галимнәреннән). – Шура. – 1914. – № 10. – Б. 290.

[17] Шәрәф Ш. Мәрҗанинең тәрҗемәи хәле / Ш. Шәрәф // Мәрҗани: Шиһабеддин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең вәлядәтенә йөз ел тулу (1233–1333) мөнәсәбәтилә нәшер ителде. – Казан: «Мәгариф» матбагасы: Нашире Салих бине Сабит Гобәйдуллин, 1333 (1915). – Б. 73.

суфи-ишаннарны милләтне таркатучылар, милләт дошманнары, милләтне бетерүчеләр, милләтне кимерүчеләр, үләксә ашаучы сыртланнар, ә аларга иярүчеләрне исә куяннар, бичаралар, милләтне аздыручылар, ахмаклар, шарлатаннар дип атаган[18]. Шунысы кызык: Тукай да, Ш. Мәрҗани кебек, чын мөршид – Коръән, дип санаган[19].

XIII гасырдан ук башлап татар кабер ташларына, мәет хакындагы мәгълүматтан тыш, Коръән аятьләре язу киң таралыш тапкан. Борынгы татар ташъязмаларында иң еш урын алган Коръән аятьләре – «Гыймран» сүрәсенең 185 нче аяте, «Әнбия» («Пәйгамбәрләр») сүрәсенең 35 нче аяте, «Ганкәбүт» («Үрмәкүч») сүрәсенең 57 нче аяте, «Әр-Рахмән» («Рәхимле») сүрәсенең 26 нчы аяте, «Локман» сүрәсенең 34 нче аяте, «Бәкара» («Сыер») сүрәсенең 155 нче аяте, «Касас» («Хикәя») сүрәсенең 88 нче аяте. Алар XX гасыр башына хәтле бик киң кулланышта булган, бигрәк тә Казан арты төбәгендә әлеге аятьләр язылган гаять күп сандагы эпиграфик истәлекләр сакланып калган. Аятьләр белән бергә кайбер очракларда Мөхәммәд пәйгамбәрнең сүзләре, ягъни хәдисләр язылган. Бу күренеш бигрәк тә Казан ханлыгы чоры эпитафияләре өчен хас. Шунысы кызык: милләтебезнең мәшһүр дин галимнәре, шул исәптән Ш. Мәрҗани, кабер ташларына Коръән-хәдистән нәрсә дә булса язуны өнәп бетермәгәннәр. Мәсәлән, Р. Фәхретдин түбәндәгечә язып калдырган: «Оренбург, Уфа, Казан шәһәрендәге каберлекләрдә гарәпчә язылган язулар бик күп күренә. Бу да тиешсез эш. Кабер ташлары нотык һәм хөтбәләр язылачак дәфтәрләр, матур язу күнегүләре өчен кара такталар түгел. Шуның өчен

[18] Тукай Г. Актык тамчы яшь: шигырьләр / Г. Тукай; төз. һәм кереш сүз авт. Л. Шәех. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. – Б. 36–37.

[19] Шунда ук. – Б. 36.

мәрхүмнең исеме, гаилә һәм фамилиясе дөрес язылу, туу һәм вафат көннәре хатасыз теркәлү җитә». Шул сәбәпледер, олуг галимнәр Ш. Мәрҗани, Р. Фәхретдин, Г. Баруди һәм аларның туганнары белән бәйле кабер ташларында Коръән аятьләре язылмаган. Мәрҗани үзе ясатып куйган ташбилгеләрнең берсендә дә Коръән аятьләре һәм хәдисләр язылмаган, димәк, моны ул кирәкле эш дип санамаган.

Галим кабер ташларына фәкать гарәп телендә һәм даталарны да һиҗри ел исәбе белән язу яклы булган. Ул үзе моны: «Һиҗри ел исәбе – сәхабәләрнең үзара килешүләре белән мөселманнар өчен һәртөрле мөгамәләләрендә тотуны һәм гамәлдә куллануны тиешле күргән ел исәбе», – дип аңлаткан[20]. Шуңа күрә Мәрҗани үзе ясаткан кабер ташларындагы текстларның барысы да гарәп телендә һәм даталары милади ел исәбе белән бирелмәгән.

Кыскасы, Шиһабетдин хәзрәт белән бәйле ташъязма истәлекләрне җентекләп өйрәнү, анализлау аша, аның кайбер фикер-карашларын ачыкларга, башка төрле чыганаклардан ала алмаган күпме мәгълүмат тупларга мөмкин.

Мәрҗани белән бәйле эпиграфик истәлекләрне өйрәнү максатыннан, без Татарстанның Арча һәм Әтнә районнары зиратларында, шулай ук Казан шәһәренең Яңа бистә каберстанында хәзерге көннәргә кадәр юкка чыкмыйча сакланып калган бөтен ташъязма истәлекләрне барлау һәм өйрәнү өчен 2015–2017 елларда берничә фәнни экспедициягә чыктык. Шул рәвешле, урта гасырлардан алып XX гасыр башларына хәтле вафат булган кешеләргә куелган гарәп

[20] Баруди Г. Ошбу әсәрне туплау мөнәсәбәте белән остаз Галимҗан бине Мөхәммәдҗан әл-Баруди хәзрәтләре язган әсәр / Г. Баруди // Мәрҗани: фәнни-популяр җыентык. – Казан: Җыен, 2010. – Б. 555.

язулы кабер ташларының һәрберсен эзләп табып, фотога төшердек, үлчәмнәрен алдык һәм текстларын укыдык. Шул рәвешле, Казан һәм Буа шәһәрләре, Арча районының Ташкичү, Кысна, Байкал һәм Иске Ашыт авыллары зиратларында Мәрҗанигә бәйле 20 ташъязма истәлек табылды, аларның барысы да игътибарыгызга тәкъдим ителә торган әлеге китапта тулаем чагылды.

Хезмәтебездә китерелгән ташбилгеләрнең татар телендәге текстларын да хәзерге заман кешесенә аңлавы кыен, чөнки бик күп гарәп-фарсы алынмалары, борынгы төрки сүзләр, архаизмнар белән чуарланган. Шуңа күрә халык укысын, аңласын өчен һәр таш текстының хәзерге татар теленә күчермәсе дә бирелде, шактый күп очраган гарәп телендәге җөмләләр һәм сүзләр тәрҗемә ителде. Шунысын искәртәбез: борынгы эпитафик текстны хәзерге татар теленә күчергәндә күп очракта юллардагы сүзләр урыннары белән алмашына, шуңа күрә алар тәңгәл килмәскә дә мөмкин. Мәсәлән, гарәп телендәге җөмләдә фигыль башка сүз төркемнәреннән алда, ә татар телендә ул һәрвакыт артка куела, шул сәбәпле, юлдан юлга тәрҗемә итеп булмый. Иске татар телендә, гарәп теленнән калькалаштыру аркасында, фигыльне җөмлә башына кую очраклары еш күзәтелә, андый очракларда да фигыльне җөмлә ахырына куеп, хәзерге татар теленә күчердек.

Кабер ияләре хакында кыскача мәгълүмат язылды, һиҗри (мөселман) календаренә нигезләнеп бирелгән даталар милади (европача) ел исәбенә күчерелде. Ташъязма истәлекләрнең үлчәмнәре дә китерелде: башта буен, аннары киңлеген, соңыннан калынлыгын күрсәтеп яздык. Мәсәлән, 100x40x10 саннары язылган булса, ташның буе – 100 см, киңлеге – 40 см, калынлыгы – 10 см дигәнне аңлата. Шулай

ук кайбер ташбилгеләр махсус нигез өстенә утыртылган, андый очракта гомуми буе җәяләр эчендә күрсәтелде.

Ш. Мәрҗани тәрҗемәи хәлен, эшчәнлеген һәм иҗатын өйрәнгәндә аның белән бәйле бернәрсәне дә игътибардан читтә калдырырга ярамый. Шуңа күрә без, бөек галимебез турында материалны җыю һәм тулыландыру йөзеннән, архив документларын, хатирәләрне, язма чыганакларны гына түгел, эпиграфик истәлекләрне дә барларга һәм өйрәнергә тиешбез. Гомумән, тарихи чыганак буларак гарәп язулы кабер ташларының әһәмияте зур, алар кыйммәтле тарихи-мәдәни истәлекләр булып санала, шуңа күрә андый эпиграфик истәлекләрне, ничек булса да, саклап калу зарур.

# МӘРҖАНИ ҺӘМ АНЫҢ ТУГАННАРЫНЫҢ ТАШБИЛГЕЛӘРЕ

## КАЗАН ШӘҺӘРЕНЕҢ ЯҢА ТАТАР БИСТӘСЕ ЗИРАТЫ

### 1. Шиһабеддин Баһаведдин улы Мәрҗанигә куелган кабер ташы, 1889 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):

1) «Мәрхүм Шиһабеддин бине Баһаэддин
2) Мәрҗани
3) хәзрәтләринең җәмегъ итдеге асаре
4) фазыл вә кәмалинә борһан катыйгдыр бәлдәи Казанда
5) кырык сәнә микъдары ләвазиме имамәт вә нәшре голүм идеб
6) 1306 сәнә һиҗриййә шәгъбан мөбарәкнең ахыр йәүмендә
7) 73 синнендә иртихаль даре бәка әйләде рахимә-һүллааһү Тәгааләә рахмәтән вәәсигаһ».

Уң ягы (уеп язылган[1]):

1) «Нәзым
2) әл-мәүтү фииһи күллүн-нәәси йәштәрикүү
3) вә ләә сүүкатүн йәбкаа вә ләә мәлик».

[1] Диагональ буенча язылган.

Сул ягы (уеп язылган[2]):

1) «Нәзым
2) ә-ләә иннәмәәд-дүнйәә кә-зыйлли сәхәәбәтин
3) әзалләткә йәүмән сүммә ганкә идъмәхәлләт
4) фә-ләә тәккә фәрхәәнән биһәә хиинә әкъбәләт
5) вә ләә тәккә җәзәгаанән ләһәә хиинә вәлләт».

Арткы ягы (уеп язылган):

1) «Мәшһәдүл-имәәми галләәмәтил-гаалими
2) саахибит-тәсаанииф-
3) –ил-фәәикати вәт-тәхкыйкаатир-рааикати Шиһабеддин бине
4) Баһаэддин әл-Мәрҗани иртәхәлә иләә рахмәти
5) Раббиһи тәгаммәдәһү Сүбхәәнәһү би-гафвиһи вә кәрамиһи гашиййәтә йәүмил-әхәди
6) ли-ләйләтин бәкыййәтин мин шәгъбәәнин сәнәтә 1306
7) ситтә бәгъдә әлфин вә сәләәсәмиъәтин минәл-һиҗраһ».

## Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:

1) «Мәрхүм Шиһабеддин бине Баһаведдин
2) Мәрҗани
3) хәзрәтләренең җыйган әсәрләре –
4) хөрмәт һәм камиллегенә катгый дәлил. Казан шәһәрендә
5) кырык ел микъдары имамлык вазыйфаларын [үтәп] һәм гыйлемнәр таратып,
6) һиҗри 1306 ел мөбарәк шәгъбаненең ахыргы көнендә

[2] Диагональ буенча язылган.

7) 73 яшендә мәңгелек дөньяга күчте. Аллаһ Тәгалә аны киң рәхмәте белән рәхим кылсын».

Уң ягы:

1) «Шигырь:
2) Үлем алдында һәр кеше бертигез,
3) гади халык та, патша да».

Сул ягы:

1) «Шигырь:
2) Чынлыкта, дөнья болыт күләгәсе кебек:
3) бүген сине күләгәдә тота, соңыннан югала.
4) Ул килгән вакытта, аңа шатланма
5) һәм, ул киткән чакта, аның өчен кайгырма».

Арткы ягы:

1) «Имам, күренекле галим,
2) бик яхшы әсәрләр
3) һәм гүзәл хезмәтләр иясе Шиһабеддин бине
4) Баһаведдин Мәрҗани кабере. Раббысы
5) рәхмәтенә (Аллаһ Сөбханәһү аны гафу итсен һәм хөрмәтләсен) кич белән якшәмбе көн
6) һижри 1306 (мең өч йөз алтынчы) елның
7) шәгъбаны тәмамланырга бер төн кала күчте».

Таш үлчәмнәре: 206(223)х52–55х35–38.

*Китапның кушымтадагы фотосын кара: б. 61, №№ 1, 1а, 1ә, 1б.*

Ш. Мәрҗани каберенә көрән төстәге граниттан эшләнгән зур, мәһабәт бер таш куелган. Аның ташының тексты гарәп графикасында татар һәм гарәп телләрендә

язылган, вафат булу датасы һиҗри ел исәбе белән күрсәтелгән.

1911 елда Ризаэтдин Фәхретдин якын дусты һәм фикердәше Галимҗан Баруди белән бергә Мәрҗани каберен зиярәт кылган. Шул вакытта ул ташның тулы текстын язып алып, аны үзенең хезмәтендә теркәп калдырган[3]. Әмма шунысы бар: Р. Фәхретдиннең тексты белән хәзерге вакытта сакланган таш тексты арасында бераз аерма бар. Мәсәлән, аның укылышыннан аермалы буларак, «Мәәтәлгаалимү вә мәәтәл-гааләм» җөмләсе хәзерге ташта юк. Шулай ук «Рахимәһүллааһү Тәгааләә рахмәтән вәәсигаһ» җөмләсендә Р. Фәхретдин текстында «Тәгааләә» сүзе төшеп калган. Башка җирләре исә туры килә. Димәк, Мәрҗани вафат булганнан соң куелган кабер ташы соңыннан икенчегә алыштырылган, дип әйтергә нигез бар.

Галимнең беренче ташы Гобәйдулла исемле шәкерте тарафыннан утыртылган булган[4]. XX гасыр башында Мәрҗани кабер ташы тузган булуы хакында Борһан Шәрәф болай язып калдырган: «Шиһаб ахунд»ның кабер ташы берничә заманнар Казан мәкъбәрәсендә иң гүзәл таш булып торган иде. Инде таш өстендәге тулы айның алтыны бетеп, бөтенләй кызганыч хәлдә калган»[5]. Элек Мәрҗанигә куелган таш өстендә тулган ай торган. Г. Тукай үзенең мәшһүр «Шиһаб хәзрәт» шигырендә юкка гына галимне тулган ай белән чагыштырмаган:

«Кирәк булса, әйтеп бирәм: ул шәп хәзрәт,
Тулган ай күк балкып чыккан Шиһаб хәзрәт,

[3] Фәхреддинев Р.С. Болгар вә Казан төрекләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. – Б. 179–180.

[4] Фәхреддин Р. Мәрҗани / Р. Фәхреддин // Мәрҗани: фәннипопуляр җыентык. – Казан: Җыен, 2010. – Б. 420.

[5] Шәрәф Б. Мәрҗани хакында җавапларым / Б. Шәрәф // Шура. – 1911. – № 24. – Б. 759.

Мәгарифкә әүвәл башлап адым салган,
Милләт өчен бәһа җитмәс кыйбат хәзрәт».

Әле 2017 елга хәтле ул тулган ай бар иде, ләкин узган ел аны ак төстәге ярымай сурәтенә алыштырып куйганнар. Әгәр дә элеккесе урынына тагын шундый ук яңа тулган ай сурәте куйган булсалар, яхшырак һәм дөресрәк булыр иде.

Мәрҗанинең кабере зиратның 15 һәм 16 нчы аллеялары арасында.

## 2. Дамелла Габденнасыйр Рахманкол улына куелган кабер ташы, 1837 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «Әл-хүкмү лилләәһ һүвәл-хәййүлләзии ләә йәмүүт
2) тарих гарәбиййә илә 1252 нче йылда
3) зөлхиҗҗәнең 17 нче көнендә дамелла
4) мөдәррис Габденнасыйр бине мулла Рахманкол 58
5) йәшендә даре фәнадан даре бәкайә нәкыль итде
6) нәүвәраллааһү Тәгааләә кабраһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта. Ул – Тере, үлми торган.
2) Һижри белән 1252 ел
3) зөлхиҗҗәсенең 17 нче көнендә дамелла
4) мөдәррис Габденнасыйр бине мулла Рахманкол 58
5) яшендә фани дөньядан мәңгелек дөньяга күчте.
6) Аллаһ Тәгалә аның каберен нурландырсын».

Таш үлчәмнәре: 140х44х17.

*Китапның кушымтадагы фотосын кара: б. 62, № 2.*

Әлеге кабер иясе – Ш. Мәрҗани хатыны Бибифатыйманың газиз атасы.

Аның шәҗәрәсе түбәндәгечә: Габденнасыйр бине Рахманколый[6] бине Мөхәммәдкол бине Габдрахман бине Габделкәрим бине Бикхафиз. Чыгышы белән Тәтеш өязендәге (хәзерге Кама Тамагы районы) Бик (Бәки) авылыннан. Габденнасыйр хәзрәт Казандагы дүртенче мәчеттә («Зәңгәр мәчет») имам-хатыйб, мөгаллим вазыйфаларын башкарган, 1825 елда «Халидия» мәдрәсәсенә нигез салган. Ни өчендер Мәрҗани аның һиҗри 1251 елда вафат булуын язып калдырган[7]. «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» китабын хәзерге татар теленә күчерүче һиҗри 1251 елның зөлхиҗҗә ае милади 1835 елга туры килә, дип күрсәткән[8], чынлыкта исә, әлеге дата 1836 елга карый.

Ш. Мәрҗани бабасына, ягъни беренче хатынының атасына мондый характеристика биргән: «Мелла Габденнасыйр ахун яхшы кыяфәте, чибәрлеге, Коръәнне яхшы укуы, матур тавышлы булуы белән танылган иде. Ул, «Хәзин» һәм «Илхан» әсәрләрен укып, үзен һәм башкаларны елата иде. Кыю һәм нык, көчле һәм гайрәтле, диндар һәм гыйбадәт белән генә шөгыльләнүче буларак мәшһүр иде»[9]. Кабере зиратның 34 һәм 35 нче аллеялары арасында.

---

[6] Мәрҗани кабер иясе атасының исемен Рахманколый дип язган.

[7] Мәрҗани Ш.Б. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – Б. 286.

[8] Шунда ук. – Б. 287.

[9] Шунда ук. – Б. 287.

### 3. Нәгыймә Хөсәен кызына куелган кабер ташы, 1871 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):

1) «Нәгыймә
2) бинтел-Хөсәйен мөхәккыйк мәшһүр
3) Шиһабеддин әл-Мәрҗани никахында
4) 19 йыл микъдары мәгыйшәт идүб зөлкагдә-
5) –нең 2 сендә 1283 сәнә иртихаль бәгъдендә
6) ошбу мәкъбәрәдә дәфен иделде
7) рахимәһәәллааһү рахмәтән вәәсигаһ».

Уң ягы (уеп язылган):

1) «Гаруусүл-мәшһәди
2) вә әнүүсүл-мәркадил-кәриимәти
3) Нәгыймә бинтел-Хөсәйен
4) интәкаләт иләә дәәрил-карaари
5) вә җәннәәти тәҗрии мин тәхтиһәә-
6) –л-әнһәәр».

Сул ягы (уеп язылган):

1) «Сәнәтә әлфин вә миъәтәйни
2) вә сәмәәниинә ли-әрбәгый
3) халәүнә мин зиил-кагдәти
4) сабәәхә йәүмил-әрбәгааъ».

Арткы ягы (уеп язылган):

1) «Миладиййә илә 1871 нче йылда
2) 14 нче гыйнварда мәрхүмә Нәгыймә вакты сәхәрдә
3) вафат улды Хак Тәгаләә гарикы рәхмәт
4) әйләйә зәүҗ мөхтәрәме Мәрҗани хәзрәтләринең

5) иртәсе көн вирде лисан итдеге шигырь

6) вә әмсиинәә ләнәә әһл кә-хайраати би-фирдәүс

7) вә әсъбәхүнәә ләнәә[10] әһл кә-әннә ләм тәганн бил-әмс».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:

1) «Нәгыймә
2) бинте Хөсәен, хаклыкны эзләүче мәшһүр
3) Шиһабеддин Мәрҗани никахында
4) 19 ел яшәп, [һиҗри] 1283
5) елның 2 зөлкагдәсендә вафат булганнан соң,
6) бу кабердә җирләнде.
7) Аллаһ аны киң рәхмәте белән рәхим кылсын».

Уң ягы:

1) «Кабер кәләше
2) һәм хөрмәтле кабер кызы
3) Нәгыймә бинте Хөсәен
4) ахирәт йортына һәм асларыннан
5) елгалар агучы җәннәтләргә
6) күчте».

Сул ягы:

1) «[Һиҗри] мең ике йөз
2) сиксәненче елларның дүртенче
3) зөлкагдәсендә
4) иртә белән чәршәмбе [җирләнде]».

---

[10] Биредә хата киткән: «ләнәә» сүзе урынында «биләә» сүзе булырга тиеш.

Арткы ягы:

1) «Милади белән 1871 елның
2) 14 гыйнварында сәхәр вакытында мәрхүмә Нәгыймә
3) вафат булды. Хак Тәгалә рәхмәткә
4) күмсен. Мөхтәрәм ире Мәрҗани хәзрәтләренең
5) иртәнге көндә телендә кабатланып торган шигыре:
6) Йокыга киттек һәм безнең Фирдәвес җәннәтендәге нигъмәт кебек хатыныбыз бар иде,
7) Йокыдан тордык һәм хатынсыз без, әйтерсең, кичә ул булмаган да».

Таш үлчәмнәре: 111(142)x40x22.

*Китапның кушымтадагы фотосын кара: б. 62, №№ 3, 3а.*

Әлеге кабер иясенең шәҗәрәсе түбәндәгечә: Нәгыймә бинте Хөсәен бине Йосыф бине Исмәгыйль бине Апанай[11]. Ул һиҗри 1247 елның шәгъбан аенда, милади 1831 елда Казан шәһәрендә дөньяга килгән[12]. Бибинәгыймә – Ш. Мәрҗанинең икенче сөекле хатыны. Шиһабетдин хәзрәт аңа һиҗри 1268 елның зөлкагдәсендә (милади 1852 елның сентябрендә) өйләнгән[13]. Нәгыймәнең кабер ташы текстында бераз ялгышлык киткән, чөнки вафат булуы, һиҗри 1283 елда, дип күрсәтелгән, чынлыкта исә, милади 1871 ел һиҗри 1287 елга туры килә. Кабере 22 нче аллея һәм зират киртәсе арасында.

---

[11] Әхмәтҗанов М.И. Татар шәҗәрәләре / М.И. Әхмәтҗанов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. – Б. 403.

[12] Мәрҗани Ш.Б. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – Б. 362.

[13] Шунда ук. – Б. 359.

**4. Мәхмүд Шиһабеддин улы Мәрҗанигә куелган кабер ташы, 1885 ел.**

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):

1) «Мәшһәд-
2) –үш-шәәббил-галләәмәти
3) Баһаэддин Әбүл-Фазыл
4) Мәхмүд бине Шиһабеддин
5) әл-Мәрҗани интәкадә иләә
6) рахмәти Раббиһи сәхәра йәүмил-хамииси ли-гашрин
7) халәүнә мин шәһри рабиигыйль-әүвәли
8) сәнәтә 1303 сәлә[сә] бәгъдә әлфин вә сәләәсәмиъәтин минәл-һиҗраһ».

Уң ягы (уеп язылган): «Иләәһии габдүкәл-гаасыый әтәәкә мүкыйрран биз-зүнүүби фә-кад дәгаакә фә-ин тәрхәм фә-әнтә әһлүн ли-зәәкә вә ин тәтъруд вә мән йәрхәм сивәәк».

Сул ягы (уеп язылган): «Йәә вәәкыйфән би-кабрии мүтәфәккиран би-әмрии бил-әмси күнтү мислүкә гадән тәсыыйру мислии».

Арткы ягы (уеп язылган):

1) «Вәәдыйгу
2) һәзәәл-ләүхи
3) вәәлидүһү Шиһабеддин
4) бине Баһаэддин
5) әл-Мәрҗани сәнәтә 1306
6) ситтә бәгъдә әлфин вә сәләәсәмиъәһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:

1) «Күренекле
2) яшь галим
3) Баһаведдин Әбел-Фазыл
4) Мәхмүд бине Шиһабеддин
5) Мәрҗани Раббысы
6) рәхмәтенә таң атканчы пәнҗешәмбе көн
7) һиҗри 1303 (мең өч йөз өченче) елның
8) унынчы рабигыль-әүвәлендә күчте».

Уң ягы: «Илаһым, синең гөнаһлы колың Синең яныңа гөнаһлар белән килде һәм Сиңа ялварды. Әгәр рәхим кылсаң, Син моны эшли аласың, әгәр куып җибәрсәң, Синнән башка кем рәхим кылсын».

Сул ягы: «Әй, минем каберем янында басып торучы, минем хәлем хакында фикерләүче, кичә мин синең кебек идем, таңда син минем кебек булырсың».

Арткы ягы:

1) «Бу ташны
2) куючы:
3) аның атасы Шиһабеддин
4) бине Баһаведдин
5) Мәрҗани, 1306 (мең
6) өч йөз алтынчы) ел».

Таш үлчәмнәре: 134х36х18.

*Китапның кушымтадагы фотосын кара: б. 63, №№ 4, 4а.*

Әлеге кабер иясе – Ш. Мәрҗанинең сөекле улы. Ул һиҗри 1283 елның 27 җөмадиәл-әүвәлендә (1866 елның октябрендә) дөньяга килгән[14]. Бик зиһенле булуы сәбәпле, Мәрҗани үзе аңа бик күп өметләр баглаган булган. «Мөстәфадел-әхбар» китабында Мәхмүдкә атасы түбәндәгечә характеристика биргән: «Гаять акыллы. сабыр, укырга бик ярата торган, яхшы хәтерле, күп нәрсәне яттан белгән, бик күп яхшы сыйфатларны үзендә туплаган, нечкә билле, матур йөзле, төз һәм озын буйлы, кара кашлы, кара күзле, кара чәчле кеше иде»[15]. Кызганычка каршы, Мәхмүд аягына салкын тидереп, бер аягын ампутацияләгәннәр, соңра инде дәваланды дигәндә генә туберкулез авыруы белән каты чирли башлап, бик яшьли вафат булган». Кабер ташындагы текстган аңлашылганча, Мәхмүднең икенче исеме, ягъни кушаматы – Баһаветдин, күньясе – Әбел-Фазыл. Кабере зиратның 15 һәм 16 нчы аллеялары арасында.

## 5. Марзыя дамелла Борһанеддин кызы Мәрҗанигә куелган кабер ташы, 1915 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):

1) «Кабер гыйбрәт урыны
2) тарих һиҗриләә 1333 сәнәдә җөмади ахир 15 ндә
3) Марзыя дамелла Борһанеддин
4) әл-Мәрҗани кәримәсе ун
5) йәшдә бу мәнзилгә назилә улды
6) априлнең 16 сында 1915 миладиййә».

---

[14] Мәрҗани Ш.Б. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – Б. 350.

[15] Шунда ук. – Б. 350.

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:

1) «Кабер – гыйбрәт урыны.
2) Һиҗри белән 1333 елның 15 җөмадиәл-ахирендә
3) Марзыя дамелла Борһанеддин
4) Мәрҗани кызы ун
5) яшьтә милади 1915 [елның]
6) 16 апрелендә бу урынга иңде.».

Таш үлчәмнәре: 84х31х13.

*Китапның кушымтадагы фотосын кара: б. 62, № 5.*

Әлеге кабер иясе – Ш. Мәрҗанинең оныгы. Кабере зиратның 14 һәм 15 нче аллеялары арасында.

**6. Борһанеддин Шиһабеддин улы Мәрҗанигә куелган кабер ташы, 1916 ел.**

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):

1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) түвүффийәш-шәйху Борһанеддин
3) Мөхәммәд бине Шиһабеддин әл-Мәрҗани фии гашиййәти
4) йәүмил-әрбәгааъи ли-ихдәә гашәра ләйләтән халләт мин
5) җүмәдииәл-үүләә әрбәга вә сәләәсиинә бәгъдә әлфин вә сәләәсәмиъәһ».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Җәгаләллааһү Тәгааләә
2) кабраһү раудатән мин рийәәдыйль-җәннәһ
3) Борһанеддин хәзрәт Казан шәһәрендә
4) 35 йыл микъдары имамәт вә тәдрис илә
5) гомер кичүреб 62 йәшендә даре бәкайә кайтды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Хөкем Аллаһта.
2) Шәех Борһанеддин
3) Мөхәммәд бине Шиһабеддин Мәрҗани кич белән
4) чәршәмбе көн мең өч йөз утыз дүртенче елның
5) унберенче җөмадиәл-әүвәлендә вафат».

Арткы ягы:
1) «Җәгаләллааһү Тәгааләә
2) кабраһү раудатән мин рийәәдыйль-җәннәһ
3) Борһанеддин хәзрәт Казан шәһәрендә
4) 35 йыл микъдары имамәт вә тәдрис илә
5) гомер кичүреб 62 йәшендә даре бәкайә кайтды».

Таш үлчәмнәре: 135х44х18.

*Китапның кушымтадагы фотосын кара: б. 63, №№ 6, 6а.*

Әлеге кабер иясе – Ш. Мәрҗанинең газиз улы. Ул һиҗри 1272 елның 19 рамазанында (1856 елның 10 маенда) дөньяга килгән[16]. Башлангыч белемне атасыннан алган, аннан

[16] Тәрҗемани К. Борһанетдин Мәрҗани хәзрәт / К. Тәрҗемани // Кояш. – 1916. – 6 март. – Б. 2.

Истамбулда җиде ел укыган. Башта 1882 елның 1 сентябрендә указ (№6436) алып, Ш. Мәрҗани белән бергә имам-мөдәррис вазыйфаларын башкарган, соңрак атасы вафат булгач, аның эшен дәвам иткән[17]. Кабер ташындагы тексттан аңлашылганча, аның чын исеме – Мөхәммәд, икенче исеме, ягъни кушаматы – Борһанетдин, күньясе – Әбел-Габбас. «Мәрхүм хуш мәҗлесле, йомшак табигатьле, гыйлем һәм хөрмәт иясе, ачык сөйләү һәм ягымлы телгә ия һәм шулар белән күп мөдәррисләрдән артык иде»[18]. Борһан хәзрәт 2 мартта кичке сәгать 5 тә, үпкәсе шешүе сәбәпле, вафат булган[19]. Хәзрәтнең үзеннән соң 5 улы, 2 кызы һәм хатыны калган. Бакыйлыкка күчкән вакытында олы улы «Мәрҗани» мәдрәсәсендә мөгаллим, икенчесе сәүдәгәр булган, калган өчесе сәүдә мәктәбендә укыганнар. Кызларының олысы Габдулла бине Галим Агишевта (чыгышы Саратов шәһәреннән) кияүдә, кечесе әле сабый бала булган[20]. Кабере зиратның 15 һәм 16 нчы аллеялары арасында.

### 7. Маһирә Сәгъдеддин кызы Мәрҗанигә куелган кабер ташы, 1920 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):

1) «Әл-мәүтү гыйбраһ
2) Маһирә Сәгъдеддин
3) кызы Мәрҗанийә

---

[17] Мәрхүм мулла Борһанетдин Мәрҗани // Кояш. – 1916. – 4 март. – Б. 2.

[18] Шунда ук. – Б. 2.

[19] Шунда ук. – Б. 2.

[20] Шунда ук. – Б. 2.

4) Габдулла зәүҗәсе
5) 43 йәшендә
6) 1338 сәнә һиҗриййә
7) април 7 ндә
8) 1920 сәнә
9) рәҗәб 18 ндә мәдфүнә
10) рахимәһәаллааһү рахмәтән
11) вәәсигаһ».

Уң ягы (уеп язылган): «Гафәраллааһү зүнүүбәһәә».

Сул ягы (уеп язылган): «Җәгаләллааһү кабраһәә раудатән мин рийәәдыйль-җәннәһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Үлем – гыйбрәт.
2) Маһирә Сәгъдеддин
3) кызы Мәрҗани –
4) Габдулла хатыны –
5) 43 яшендә
6) һиҗри 1338 елның
7) 18 рәҗәбендә,
8) [милади] 1920 елның
9) 7 апрелендә җирләнде.
10) Аллаһ аны киң рәхмәте белән
11) рәхим кылсын».

Уң ягы (уеп язылган): «Аллаһ аның гөнаһларын кичерсен».

Сул ягы (уеп язылган): «Аллаһ аның каберен җәннәт бакчаларыннан бер бакча итсен».

Таш үлчәмнәре: 111x31x16.

*Китапның кушымтадагы фотосын кара: б. 64, № 7.*

Әлеге кабер иясе – галимнең ерак туганы булса кирәк, әмма Маһирә исемле хатын-кыз аңа ничек туган икәнен ачыклап булмады. Мәрҗани энесе Садретдин хәзрәтнең Габдулла исемле улы булган, бәлки, ул шуның хатыныдыр. Кабер иясенең фамилиясе Мәрҗани дип язылганга күрә, без бу ташбилгенең текстын биредә китерергә булдык. Кабере зиратның 20 һәм 22 нче аллеялары арасында.

**8. Габделхәмид Борһанеддин улы Мәрҗанигә куелган кабер ташы[21], 1921 ел.**

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган[22]):
1) «Габделхәмид
2) бине Борһанеддин
3) Мәрҗани
4) 1885 – 1921
5) Габдельхәмид
6) Борханеддин
7) улы
8) Мәрҗәни».

---

[21] Әлеге кабер ташы борынгы түгел, шулай булса да, Мәрҗанинең оныгына куелганга күрә, игътибарга лаек.

[22] Беренче өч юлы гарәп графикасында, калганнары кириллицада язылган.

Таш үлчәмнәре: 102(126)х39х7.

*Китапның кушымтадагы фотосын кара: б. 64, № 8.*

Әлеге кабер иясе – Ш. Мәрҗанинең оныгы. Габделхәмид хәзрәт 1917 елның 27 гыйнннварында указ (№324) алып, «Мәрҗани» мәчетендә, бабасы һәм атасы шикелле, имам-хатыйб вазыйфасын башкарган. Кабере зиратның 17 һәм 18 нче аллеялары арасында.

**9. Габделгазиз Борһан улы Мәрҗанигә һәм Ильяс Борһан улы Мәрҗанигә куелган кабер ташы, 1921 һәм 1923 еллар.**

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Габделгазиз Борһан
2) хәзрәт углы Мәрҗани
3) 1921 нче йыл
4) дикәбр 30 нда
5) 28 йәшендә вафат
6) Аллаһ рәхмәт кыйлсун
7) амин».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Илйас Борһан
2) хәзрәт углы Мәрҗани
3) 1923 нче йыл
4) агуст 31 ндә
5) 27 йәшендә вафат

6) әнкәсе тарафындан
7) тәзкирә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Габделгазиз Борһан
2) хәзрәт улы Мәрҗани
3) 1921 елның
4) 30 декабрендә
5) 28 яшендә вафат.
6) Аллаһ рәхим кылсын,
7) амин».

Арткы ягы:
1) «Ильяс Борһан
2) хәзрәт улы Мәрҗани
3) 1923 елның
4) 31 августында
5) 27 яшендә вафат.
6) Әнкәсе тарафыннан
7) истәлек».

Таш үлчәмнәре: 93(106)x36x12.

*Китапның кушымтадагы фотосын кара: б. 64, №№ 9, 9а.*

Әлеге кабер ияләре – Ш. Мәрҗанинең оныклары. Аларның икесенә бер таш куелган. Каберләре зиратның 14 һәм 15 нче аллеялары арасында.

**10. Галия дамелла Шиһабеддин кызына куелган кабер ташы, 1924 – 1925 еллар.**

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Мәшһүрә ханым
2) Галийә
3) бинте дамелла
4) Шиһабеддин
5) Мәрҗани
6) кабләл-гурууби
7) мин йәүмил-җүмгати
8) 1343 сәнәи һиҗриййә
9) 71 йәшендә
10) мәдфүнә рахимәһәллаһү
11) Тәгааләә рахмәтән вәәсигаһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Мәшһүрә ханым
2) Галия
3) бинте дамелла
4) Шиһабеддин
5) Мәрҗани
6) кояш батар алдыннан
7) җомга көн
8) һиҗри 1343 елда
9) 71 яшендә

10) җирләнде. Аллаһ Тәгалә аны киң
11) рәхмәте белән рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 102(117)х28–31х16–20.

*Китапның кушымтадагы фотосын кара: б. 65, № 10.*

Әлеге кабер иясе – Ш. Мәрҗанинең олы кызы. Ул гыйлемне үз атасыннан алган. Аның Ш. Мәрҗани аны үз шәкерте Сафиулла бине Габдуллага кияүгә биргән[23]. Галиянең икенче исеме, ягъни кушаматы – Хәерниса, күньясе – Өммехәер. Г. Баруди аңа түбәндәгечә характеристика биргән: «Коръәнне яттан белүче, гарәпчәгә сәләтле, аңлау һәм фикер йөртүдә атасыннан күп белемнәр алган, Коръән бастыру эшендә хезмәт итешкән, Нәгыймә исемле бер кыз анасы, күркәм хатын»[24]. Кабере зиратның 17 һәм 18 нче аллеялары арасында.

[23] Шәрәф Ш. Мәрҗанинең тәрҗемәи хәле / Ш. Шәрәф // Мәрҗани: фәнни-популяр җыентык. – Казан: Җыен, 2010. – Б. 124.

[24] Баруди Г. Остаз Шиһабеддин әл-Мәрҗани хәзрәтләре / Г. Баруди // Мәрҗани: фәнни-популяр җыентык. – Казан: Җыен, 2010. – Б. 398.

## 11. Хавва Шиһабеддин кызына һәм Зәйнәб Габдулла кызы Апанаевага куелган кабер ташы[25], 1945 һәм 1987 еллар.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган[26]):
1) «Шиһабеддин Мәрҗани
2) кызы Хавва Апанайыва
3) 1871 – $^{20}/_{V}$ 1945
4) Аллаһ рәхмәт кыйлсун
5) Апанаева
6) Хавва
7) Марджани кызы».

Арткы ягы (уеп язылган[27]):
1) «Апанайыва Зәйнәб
2) Габдулла кызы
3) Шиһабеддин Мәрҗани
4) онугы
5) *9.III* 1903 – 1987 *25.I*
6) Апанаева
7) Зәйнәб
8) Габдулла кызы».

---

[25] Әлеге кабер ташы борынгы түгел, шулай булса да, Мәрҗанинең кызына куелганга күрә, игътибарга лаек.

[26] Беренче ике һәм дүртенче юллары гарәп графикасында, калганнары кириллицада язылган.

[27] Беренче дүрт юлы гарәп графикасында, калганнары кириллицада язылган.

*Китапның кушымтадагы фотосын кара: б. 65, №№ 11, 11а.*

Әлеге аналы-кызлы кабер ияләре – Ш. Мәрҗанинең кызы һәм оныгы. Хавваның икенче исеме, ягъни кушаматы – Ситтел-бәнат, куньясе – Өмме Әйман. Казанның Печән базары мәчете имамы Әбү Яхъя Габдулла Апанаевка кияүгә чыккан. Баруди хәзрәт Хавва ханымны: «Мәгърифәт һәм аң иясе булган хатын», – дип телгә алган[28]. Кызы Зәйнәпнең шәҗәрәсе түбәндәгечә: Зәйнәп бинте Габдулла бине Габделкәрим бине Исхак бине Йосыф бине Исмәгыйль бине Апанай[29]. Кабере зиратның 15 һәм 16 нчы аллеялары арасында.

---

[28] Баруди Г. Остаз Шиһабеддин әл-Мәрҗани хәзрәтләре / Г. Баруди // Мәрҗани: фәнни-популяр җыентык. – Казан: Җыен, 2010. – Б. 398.

[29] Шунда ук. – Б. 398.

## 12. Мәкнүнә Галәведдин кызына куелган кабер ташы, 1905 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Саахибәтү һәзә-
2) -әл-кабри Мәкнүнә
3) бинте Галәэддин
4) әл-Мәрҗани 1322 сәнәи
5) һиҗриййә зөлхиҗҗәнең
6) 2 нче йәүмендә сәнәи
7) шәмсиййә берлән 5
8) 1905 нче 25 нче
9) гыйнварда 24 йәшендә
10) җан әманәтене
11) кабдыль-әрвахиһ»[30].

Уң ягы (уеп язылган): «Үхърус ли-дүнйәәкә кә-әннәкә тәгыййшү әбәдәә».

Сул ягы (уеп язылган): «Вә игъмәл ли-әәхыйратикә кә-әннәкә тәмүүтү гадәә».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «тәслим итде вә
2) рихләте даре бәкайә әйләде

[30] Дәвамы арткы ягында.

3) иннәә лилләәһи вә иннәә иләйһи раа-
4) –җигуун мәрхүмә-
5) –нең фәрзәнд газизләре
6) Фатыйма вә Габд-
7) –елхак тарафлары-
8) –нда мәдфүн
9) әл-кабру раудатүн мин рийәәд-
10) -ыйль-җәннәти әү хүфратүн мин
11) хүфратин-нәйраан»[31].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Бу кабер
2) иясе Мәкнүнә
3) бинте Галәведдин
4) Мәрҗани һиҗри1322 ел
5) зөлхиҗҗәсенең
6) 2 нче көнендә
7) милади белән
8) 1905 [елның] 25
9) гыйнварында 24 яшендә
10) җан әманәтен
11) алып, рух».

Уң ягы: «Бу дөнья өчен, мәңге яшәячәксең кебек тырыш».

Сул ягы: «Ахирәт өчен, иртәгә үләячәксең кебек гамәл кыл».

[31] Башы алгы ягында.

Арткы ягы:

1) «тәслим кылды
2) һәм мәңгелек дөньяга күчте.
3) Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм, чынлыкта, Аңа
4) кайтачакбыз. Мәрхүмә-
5) –нең газиз балалары
6) Фатыйма вә Габд-
7) –елхак тарафлары-
8) –нда җирләнде.
9) Кабер – җәннәт бакчаларыннан
10) бер бакча яки утлар чокырларыннан
11) бер чокыр».

Таш үлчәмнәре: 96x32x13.

*Китапның кушымтадагы фотосын кара: б. 66, №№ 12, 12а.*

Әлеге кабер иясе – Мәрҗани энесе Галәветдин хәзрәтнең кызы. Кызганыч ки, әлеге кабер иясе бик яшьли вафат булган. Өстәвенә, аның сөекле ике баласы – Фатыйма һәм Габделхак – тугач та, озак тормыйча, үлгәннәр һәм аналары белән бергә бер тирәдәрәк җирләнгәннәр, тик балаларның каберләрендә бернинди ташбилге юк. Мәкнүнәгә куелган ташъязмада бу балаларның исемнәре телгә алынганга күрә, әлеге эпиграфик истәлек өч кеше өчен куелган. Берничә кешегә бер таш кую гадәте безнең җирлектә шактый еш күзәтелә. Мәрхүмнәрнең каберләре зиратның үзәк өлешендә.

## 13. Габделгали Габделбасыйр улына куелган кабер ташы, 1915 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):

1) «Күллү нәфсиң зәәикатүл-мәүүт
2) саахибү һәзәәл-кабри
3) имам мулла Габделгали
4) бине мулла Габделбасыйр
5) һиҗриййә илә 1333 нҗе сәнә
6) 6 нчы рабигыль-ахирдә
7) миладиййә илә 1915 нҗе сәнә
8) 7 нҗе фивралда 77
9) йәшендә мәдфүн
10) 51 сәнә имам улды».

Уң ягы (уеп язылган): «Ләү кәәнәтид-дүнйәә түдүүмү ли-вәәхидин лә-кәәнә расүүлүллааһи фииһәә мүхлидәә».

Сул ягы (уеп язылган):

1) «Бивафа дөнйайа йукдыр игътимад кеми кем идәрсә сахиб тәхтә таҗ итмәдиме шаһлары зары һәлакь
2) ул җәфакярнең әлендин дад дад йирә чалур кәс идәр мисле рәҗаҗ тәхтә шәйн икән идеб зирхакь».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:

1) «Һәр җан иясе үлемне татыячак.

2) Бу кабер иясе
3) имам мулла Габделгали
4) бине мулла Габделбасыйр
5) һиҗри белән 1333 елның
6) 6 рабигыль-ахирендә,
7) милади белән 1915 елның
8) 7 февралендә 77
9) яшендә җирләнде.
10) 51 ел имам булды».

Уң ягы: «Әгәр дә дөнья берәрсе өчен дәвам итсә, Аллаһның илчесе анда мәңге булыр иде».

Сул ягы:

1) «Тугрысыз дөньяга юктыр ышаныч, кемгә таҗ кидерде, шул кешеләрне, шаһларны һәлакь итте.

2) Ул җәфа иясе җиргә чалыр, калтыратыр, оятка калдырыр, тыгар җир астына».

Таш үлчәмнәре: 127x36x17.

*Китапның кушымтадагы фотосын кара: б. 65, № 13.*

Әлеге кабер иясе – Ш. Мәрҗанинең өч туган энесе, ягъни аңа өченче буын белән кардәш булып чыга. Ул 1840 елда дөньяга килгән, шәҗәрәсе түбәндәгечә: Габделгали бине Габделбасыйр бине Габденнасыйр бине Сәйфелмөлек бине Мозаффар бине Мортаза бине Гали бине Йосыф[32]. Бу шәхес башта Иске Ашытның беренче мәчетендә, 1882 елдан соң икенче мәчетендә имам-хатыйб вазыйфаларын башкарган (указының номеры – № 3219, 1864 елның 30 апрелендә

[32] Шунда ук. – Б. 281.

бирелгән)[33]. Аның улы Габделбари да 1890 елдан башлап Иске Ашытта имам вазыйфаларын башкарган. Габделгали хәзрәтнең кабере зиратның төньяк-көнбатыш ягында.

Арча районы Иске Ашыт авылы да Ш. Мәрҗанигә бик якын, чөнки анда аның анасы ягыннан бабасы яшәгән. Галим Иске Ашытта еш булган, шул сәбәпле, байтак вакытын бабасы Габденнасыйр белән уздырган һәм аннан төпле белем, күркәм әхлак алган. Ш. Мәрҗани аңа ташбилге куйдырган булган[34]. Кызганычка каршы, Иске Ашыт зиратында Габденнасыйр хәзрәтнең кабер ташын таба алмадык, сакланмаган булса кирәк.

## 14. Габделбәдигъ Габделгали улына куелган кабер ташы, 1910 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):

1) «Күллү нәфсиң
2) зәәикатүл-мәүүт
3) Габделбәдигъ мулла
4) Габделгали углы
5) сәнәи һиҗриййә илә 1328
6) нче 11 нче рабигыль-а-
7) –хирдә миладиййә илә 1910
8) нчы сәнә 8 нче априлдә йәүме
9) пәнҗешәнбә даре бәкайә күчде».

---

[33] ТР Милли архивы: ф. 2, тасв. 2, сак. бер. 3734. – Б. 2–17.

[34] Мәрҗани Ш.Б. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – Б. 284.

Уң ягы (уеп язылган)[35]:

1) «Йәә вәәкыйфән би-кабрии мүтәфәккиран фии әмрии
2) бил-әмси күнтү мислүкә гадән тәсыыйру мислии
3) 32 йәшендә
4) вафат».

Сул ягы (уеп язылган):

1) «Мән зәәра кабрии фәлйәкүн мүүкыйнән иннәл-ләзиил-кааһә йәлкааһ
2) фә-йәрхәмүллааһү имраә зәәрани фәкаалә лии йәрхәмүкәллааһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:

1) «Һәр җан иясе
2) үлемне татыячак.
3) Габделбәдигъ мулла
4) Габделгали улы
5) һиҗри белән 1328 елның
6) 11 рабигыль-а-
7) –хирендә, милади белән 1910
8) елның 8 апрелендә
9) пәнҗешәмбе көн ахирәт дөньясына күчте».

Уң ягы:

1) «Әй, каберем янында басып торучы, минем эшем хакында фикерлә:
2) кичә мин синең кебек идем, иртәгә син минем шикелле булырсың.

[35] Беренче ике юлы вертикаль, калган юллары горизонталь рәвештә язылган.

3) 32 яшендә
4) вафат».

Сул ягы:
1) «Минем каберемә килгән кеше ышансын: чынлыкта, мин дучар булган нәрсәгә ул да дучар булыр.
2) «Аллаһ аны рәхим кылсын», – дип минем өчен дога кылган кешене Аллаһ үзен дә рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 95(108)x31x11.

*Китапның кушымтадагы фотосын кара: б. 67, № 14.*

Әлеге кабер иясе – югарыда искә алынган Габделгали хәзрәтнең улы. Ул 1868 елның 11 мартында туган. Кабере зиратның төньяк-көнбатыш ягында.

### 15. Сөбхан Габделкәрим улына һәм Зәгыйфә Габденнасыйр кызына куелган кабер ташы, 1834 һәм 1835 еллар.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):
1) «...Сөбхан бине
2) Габделкәрим әл-Мәрҗани вә интәкалә иләә дәарилкараари вә җәннәәти
3) фии зил-хиҗҗәти сәнәтә тисгыйн вә әрбәгыыйнә
4) вә миәтәйни вә әлфин мин һиҗрати мән ләһү кәмәәлүл-гыйззи вәш-шәрәф
5) вәл-мәрҗүввү ләһү...».

Уң ягы (калкытып язылган): «Вәдага һәзәәл-ләүхә Шиһабеддин бине Баһаэддин әл-Мәрҗани 1285 сәнә».

Сул ягы (калкытып язылган): «Вә мин йәлииһи мин җәһәтил-кыйбләти халииләтүһү Зәгыйфә бинте Габделбакый түвүффийәт 1250 сәнә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «...Сөбхан бине
2) Габделкәрим әл-Мәрҗани ахирәт йортына һәм җәннәтләргә
3) мең ике йөз кырык тугызынчы елның

4) зөлхиҗҗәсендә күчте, [ел исәбе] камил дәрәҗәдәге олылык һәм хөрмәт иясе булган зат [Мөхәммәд пәйгамбәр] һиҗрәтеннән [Мәккәдән Мәдинәгә күченүеннән] соң.

5) Аңа... сорыйбыз».

Уң ягы: «Бу ташны Шиһабеддин бине Баһаведдин Мәрҗани [һиҗри] 1285 елда куйды».

Сул ягы: «Аның кыйбла ягында сөеклесе Зәгыйфә бинте Габделбакый, [һиҗри] 1250 елда вафат».

Таш үлчәмнәре: 114х36х19.

*Китапның кушымтадагы фотосын кара: б. 66, №№ 15, 15а.*

Әлеге кабер ияләре – Ш. Мәрҗанинең атасы ягыннан әби-бабасы. Шунысы кызганыч, ташбилгеләре инде тәмам җимерелеп, юкка чыгу алдында тора, өске өлеше инде ватылып төшкән.

Сөбхан хәзрәт бик күп җирләрдә гыйлем туплаган һәм күптөрле фәннәр өйрәнгән. Галич төбәгендәге Олы Җәке, Казан өязендәге Кысна авылларында имам булып торган[36]. «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» китабын хәзерге татар теленә күчерүче һиҗри 1249 елның зөлхиҗҗә

[36] Мәрҗани: Шиһабеддин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең вәлядәтенә йөз ел тулу (1233–1333) мөнәсәбәтилә нәшер ителде. – Казан: «Мәгариф» матбагасы: Нашире Салих бине Сабит Гобәйдуллин, 1333 (1915). – Б. 4.

ае милади 1833 елга туры килә, дип күрсәткән[37], чынлыкта исә, әлеге дата 1834 елга карый.

Зәгыйфәнең шәҗәрәсе түбәндәгечә: Бибизәгыйфә бинте Габделбакый бине Мөслим (Мәрҗанинең 1989 елда басылган «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» китабында бу исемне кириллицага күчергәндә нигәдер Мөсәллим дип биргәннәр, бу дөрес түгел, «Асар» хезмәтендә бу исем Мөслим дип дөрес бирелгән[38]) бине Мостафа бине Сәлим[39]. Аның вафат булу датасы кабер ташында ялгыш язылганлыгы хакында Ш. Мәрҗани үзе үк китабында искәртеп узган һәм, чынлыкта, әбисенең һиҗри 1251 (1835) елда үлгәнен һәм ташны да үзе яздыртып куйганлыгын әйткән[40]. Әлеге ташбилгене нәкъ менә Ш. Мәрҗани үз куллары белән куйган икәнлеге ташның уң ягында искәртелгән. Ул әби-бабасының икесенә бер таш кую белән чикләнгән, димәк, ике кешегә бер таш кую гадәтен галим хуплаган. Каберләре зиратның үзәк өлешендә.

[37] Мәрҗани Ш.Б. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – Б. 240.

[38] Фәхреддин Ризаэддин. Асар. 2 том. – Казан: Рухият, 2009. – Б. 68.

[39] Мәрҗани Ш.Б. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – Б. 239.

[40] Шунда ук. – Б. 240.

**16. Баһаведдин Сөбхан улына һәм Хөбәйбә Габденнасыйр кызына куелган кабер ташы, 1856 һәм 1823 еллар.**

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):

1) «Һәзәә мәркадү галләәмәтил-әнәәми
2) вә мәшһәдү фәһһәәмәтил-әгъләәмил-мүштәһәри бил-фәдъли
3) вәл-гыйльми мин бәйнә әкъраанииһи вәт-тәфәүвүкый галәә әмсәәлииһи
4) вәхиидү дәһриһи вә фәриидү гасриһи бәһәәүл-хәккый вәд-диини
5) Әбел-Галяэ Мөхәммәд бине Сөбхан бине Габделкәрим әл-Мәрҗани
6) таййибәллааһү Тәгааләә рамсәһү вә таррабә фии гааләмил-кудси нәфсәһ
7) түвүффийә йәүмәл-иснәйнил-хаамиси мин шәһри рабигыйль-әүвәли
8) сәнәтә сәләсин вә сәбгыыйнә вә миәтәйни вә әлфин вә гумруһүл-газиизү
9) кад нәййәфә галәс-сәбгыыйн».

Уң ягы (калкытып язылган): «Йәә вәәкыйфән фии кабрии тәфәккир фии әмрии кад күнтү әмси мислүкә фәтәсыыйру гадән мислии».

Сул ягы (калкытып язылган): «Тарих хәзрәт Баһаэддин әл-Мәрҗани саахибү фәдълин бикәрам».

Арткы ягы (калкытып язылган):

1) «Вә йәтлүүһү мин мәгърибиһи кабру халииләтиһ-

2) -ил-гафиифәтис-саалихәтил-бәәррати үммил-гыймә-әди

3) Хөбәйбә бинте Габденнасыйр бине Сәйфелмөлек бәррадәллааһү

4) мәәъвәһәә вә җәгаләл-җәннәтә мәсвәәһәә түвүффийәт

5) фии зил-хиҗҗәти сәнәтә сәмәәнин вә сәләәсиинә вә миәтәйни вә әлфин

6) мин һиҗрати мән ләһү кәмәәлүл-гыйззи вә тәмә-әмүш-шәрәф

7) йәә ихвәәни вә әүләәди вә әхфәәдии ләә тәгурран-нәкүм-

8) үд-дүнйәә фәиннәд-дүнйәә фәәниййәтүн вәл-әәхый-ратү әәтиййәтүн

9) вә күллү әәтин карииб».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:

1) «Бу – кешеләрнең белүчерәге,

2) гыйлем ияләре арасында белемлеге һәм аңа тиң булганнардан өстенлеге

3) белән танылган, галимнәрнең галиме булган затның кабере.

4) Үз чорының һәм заманының бердәнбере, хаклыкның һәм диннең гүзәллеге булган

5) Әбел-Галяү Мөхәммәд бине Сөбхан бине Габделкәрим әл-Мәрҗани

6) Аллаһ Тәгалә аның каберен яхшы итсен һәм изгеләр галәмендәге аның җанын шатландырсын.

7) мең ике йөз җитмеш өченче елның

8) 5 рабигыль-әүвәлендә дүшәмбе көн вафат булды, газиз гомере [яше]

9) җитмештән артты».

Уң ягы: «Әй, каберем янында басып торучы, минем эшем хакында фикерлә: кичә мин синең кебек идем, иртәгә син минем шикелле булырсың».

Сул ягы: «Юмартлык белән өстенлек иясе хәзрәт Баһаведдин Мәрҗани».

Арткы ягы:

1) «Аның көнбатыш ягында

2) тыйнак, изге, яхшы күңелле сөеклесе, терәк анасы

3) Хөбәйбә бинте Габденнасыйр бине Сәйфелмөлек кабере. Аллаһ аның

4) урынын суытсын һәм җәннәт итсен.

5) Мең ике йөз утыз сигезенче елның зөлхиҗҗәсендә вафат булды,

6) [ел исәбе] камил дәрәҗәдәге олылык һәм тулы хөрмәт иясе булган зат [Мөхәммәд пәйгамбәр] һиҗрәтеннән [Мәккәдән Мәдинәгә күченүеннән] соң.

7) Әй, кардәшләрем, балаларым, оныкларым, дөньяга

8) алданмагыз, чынлыкта, дөнья фани, аның ахыры киләчәк,

9) һәм һәр киләчәк нәрсә якын».

Таш үлчәмнәре: 104х40х17.

*Китапның кушымтадагы фотосын кара: б. 67, №№ 16, 16а.*

Әлеге кабер ияләре – Мәрҗанинең газиз ата-анасы. Шунысы кызганыч, ташбилгеләре инде тәмам җимерелеп, юкка чыгу алдында тора, текстының кайбер өлеше инде укылмаслык дәрәҗәгә килгән.

Мәрҗани 18 яшендә үзенең анасы каберенә кечкенә таш язып куйганлыгы мәгълүм[41]. Шәһәр Шәрәф «Мәрҗани» җыентыгында: «Баһаветдин вә Хөбәйбәнең кабере Ташкичүдә, икесе бергә. Соңыннан икесенә Мәрҗани тарафыннан дүрт тарафы язулы бер таш куела», – дип язган[42].

Баһаветдин хәзрәт һиҗри 1201 (1786–1787) елның рабигыль-әүвәл аенда хәзерге Яшел Үзән районы Олы Җәке авылында дөньяга килгән, тик 1989 елда басылып чыккан «Мөстәфадел-әхбәр» хезмәтендә, басмага әзерләүчесе хаталанганга күрә, Баһаветдин хәзрәт Бәрәскәдә туган, дип ялгыш язылган[43]. Шулай ук аның туган авылы Олы Җәкене дә хәзер Арча районына түгел, ә Яшел Үзән районына кергәнлеген дә искәртергә кирәк. Мәрҗанинең тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнгән тарихчыларның барысы диярлек Баһаветдин хәзрәт хәзерге Арча районы Чәки әл-Көбра авылында туган, дип язалар[44]. Чынлыкта исә, «әл-Көбра» сүзе гарәп теленнән «олы» дип тәрҗемә ителә,

---

[41] Мәрҗани: Шиһабеддин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең вәлядәтенә йөз ел тулу (1233–1333) мөнәсәбәтилә нәшер ителде. – Казан: «Мәгариф» матбагасы: Нашире Салих бине Сабит Гобәйдуллин, 1333 (1915). – Б. 6, 25.

[42] Шунда ук. – Б. 6.

[43] Мәрҗани Ш.Б. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – Б. 314.

[44] Кара: Юсупов М.Х. Шигабутдин Марджани как историк / М.Х. Юсупов. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1981. – С. 22; Марджани Ш. Зрелая мудрость в разъяснении догматов ан-Насафи (ал-Хикма ал-балига) / Шигабутдин Марджани; предисл. и пер. с араб. Д. Шагавиева. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2008. – С. 58.

ягъни Олы Җәке була. Андый исемле авыл Арча районында беркайчан булмаган һәм юк та. Олы Җәке авылы хәзерге Яшел Үзән районында урнашкан. Ул сала бик борынгы һәм ул Казан ханлыгы чорында ук билгеле булган, чөнки зиратында (тулысынча безнең тарафтан өйрәнелде) 1547 елга караган эпиграфик истәлек сакланган.

Белгәнебезчә, мулла Баһаветдин бик гыйлемле, укымышлы кеше булган, башта Ябынчы авылында, аннан Ташкичү авылында кырык елга якын имам һәм мөдәррис булып, халыкка хезмәт иткән. Ни өчендер Ш. Мәрҗани атасын һиҗри 1273 (1856) елның 25 рабигыль-әүвәлендә дүшәмбе көн вафат булды, дип язган[45]. Ташта исә шул елның 5 рабигыль-әүвәлендә икәнлеге ачык күренә.

Ш. Мәрҗанинең анасы һиҗри 1209 (1795) елның 3 рәҗәбендә туган[46]. Аның шәҗәрәсе түбәндәгечә: Хөбәйбә бинте Габденнасыйр бине Сәйфелмөлек бине Мозаффар бине Мортаза бине Гали бине Йосыф[47]. Кайберәүләр ялгыш аның исемен Хәбибә рәвешендә язалар, чөнки әлеге исемнәрнең икесе дә гарәп телендә һәм графикасында бертөрле языла. Чынлыкта исә, нәкъ менә Хөбәйбә булырга тиеш икәнлеген җәмәгать һәм дин эшлеклесе Ш. Шәрәф аңлатып язган[48]. Хәбибә Хөбәйбәнең сеңлесе, ягъни Ш. Мәрҗанинең үги әнисе булган. Галим үзенең китабында анасының вафатын төгәлрәк әйткән, ягъни һиҗри 1238 (1823) елның

---

[45] Мәрҗани Ш.Б. Әл-кыйсмес-сани мин мөстәфадел-әхбари фи әхвали Казан вә Болгар. – Казан: Казан университеты тәбгыханәсе, 1900. – Б. 132.

[46] Шунда ук. – Б. 149.

[47] Шунда ук. – Б. 147.

[48] Мәрҗани: Шиһабеддин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең вәлядәтенә йөз ел тулу (1233–1333) мөнәсәбәтилә нәшер ителде. – Казан: «Мәгариф» матбагасы: Нашире Салих бине Сабит Гобәйдуллин, 1333 (1915). – Б. 8.

8 зөлхиҗҗәсендә 29 яшь тулар-тулмас вакытында Гафифә исемле баласын тапканда үлгәнлеген язып калдырган[49].

Мәрҗанинең ата-анасы каберләре зиратның көньяк-көнчыгыш ягында.

Югарыда искә алынган ташның текстын заманында Ш. Шәрәф бастырып чыгарган булган[50], әмма ул кайбер сүзләрне укымыйча төшереп калдырган. Ш. Шәрәфнең 1915 елда «Мәрҗани» җыентыгында урын алган язмасы 1998 һәм 2010 елларда хәзерге татар теленә күчерелеп, 2015 елда рус теленә тәрҗемә ителеп, китаплар рәвешендә нәшер ителде, ләкин аларда ни өчендер бу ташъязманың эчтәлеге бөтенләй китерелмәгән.

## 17. Бибиәсма мулла Ягъкуб кызына куелган кабер ташы, 1896 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Саахибәтүл-мәркади
2) Бибиәсма мулла Ягкуб
3) кызы мулла Садреддин әл-Мәрҗани
4) зәүҗәсе 56 нчы йәшендә
5) 1314 сәнә һиҗрийәдә 10 нчы
6) рәҗәбдә 1896 сәнә румийә

[49] Мәрҗани Ш.Б. Әл-кыйсмес-сани мин мөстәфадел-әхбари фи әхвали Казан вә Болгар. – Казан: Казан университеты тәбгыханәсе, 1900. – Б. 131

[50] Мәрҗани: Шиһабеддин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең вәлядәтенә йөз ел тулу (1233–1333) мөнәсәбәтилә нәшер ителде. – Казан: «Мәгариф» матбагасы: Нашире Салих бине Сабит Гобәйдуллин, 1333 (1915). – Б. 6.

7) үктәбр 4 ндә дәфен иделде».

Уң ягы (уеп язылган): «Аллаһ Тәгалә каберине җәннәт бакчасы әйләсүн».

Сул ягы (уеп язылган): «Зүүруу фил-кубүүри фәиннәһәә түзәккируль-мәүүт».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Кабер иясе
2) Бибиәсма мулла Ягкуб
3) кызы, мулла Садреддин әл-Мәрҗани
4) хатыны 56 нчы яшендә
5) һиҗри 1314 елның 10
6) рәҗәбендә, милади 1896 елның
7) 4 октябрендә җирләнде».

Уң ягы: «Аллаһ Тәгалә каберен җәннәт бакчасы итсен».

Сул ягы: «Каберләрне зиярәт кылыгыз, чынлыкта, алар сезгә үлемне искә төшерә».

Таш үлчәмнәре: 102x36x14.

*Китапның кушымтадагы фотосын кара: б. 67, № 17.*

Әлеге кабер иясе – Мәрҗани энесе Садретдиннең хатыны. Кызганычка каршы, Ташкичү авылы зиратында ире Садретдин хәзрәтнең каберташы табылмады. Бибиәсма ханымның атасы Кышкар авылында имам һәм мөдәррис булган. Аның билгеле булган шәҗәрәсе түбәндәгечә:

Бибиәсма бинте Ягъкуб бине Яхъя бине Җәгъфәр[51]. Кабере зиратның көньяк-көнчыгыш ягында.

## 18. Галәведдин Баһаведдин улына куелган кабер ташы, 1908 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):

1) «Рахимәллааһү мән зәәрании
2) әл-гаалимүл-фәәдыйлү
3) мулла Галәэддин ибне
4) мулла Баһаэддин әл-Мәрҗани
5) руми 1908 нче сәнә 17 нче
6) април 68 йәшендә»[52].

Уң ягы (уеп язылган): «даре бәкайә рихләт әйләде»[53].

Сул ягы (уеп язылган): «Нәүвәраллааһү кабраһү вә җәгаләл-җәннәтә мәсвәәһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:

1) «Мине зиярат кылган кешене Аллаһ рәхим кылсын
2) Галим, лаеклы зат
3) мулла Галәведдин ибне
4) мулла Баһаведдин Мәрҗани

[51] Фәхреддин Ризаэддин. Асар. 2 том. – Казан: Рухият, 2009. – Б. 26.

[52] Дәвамы уң ягында.

[53] Башы алгы ягында.

5) миладиа 1908 елның 17
6) апрелендә 68 яшендә».

Уң ягы: «мәңгелек дөньяга күчте».

Сул ягы: «Аллаһ аның каберен нурландырсын һәм урынын җәннәт итсен».

Таш үлчәмнәре: 90x31x11.

*Китапның кушымтадагы фотосын кара: б. 68, № 18.*

Әлеге кабер иясе – Мәрҗанинең бертуган энесе. Шулай ук ул – күренекле татар язучысы, драматург, журналист, публицист, тәрҗемәче Мәхмүт Галәүнең атасы. Кабере зиратның көньяк-көнчыгыш ягында.

**19. Габделмөэмин Садреддин улына куелган кабер ташы[54], 1956 ел.**

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган[55]):
1) «Габделмөкмин
2) Садреддин
3) углы
4) 1868 – 1956

[54] Әлеге кабер ташы борынгы түгел, шулай булса да, Мәрҗанинең туганына куелганга күрә, игътибарга лаек.
[55] Беренче өч юлы гарәп графикасында, калганнары кириллицада язылган.

5) Габделмөкмин
6) Садертдин
7) улы».

*Китапның кушымтадагы фотосын кара: б. 68, № 19.*

Әлеге кабер иясе – Мәрҗани энесе Садретдин хәзрәтнең улы. Архив документында аның 1965 елның 13 сентябрендә туган икәне күрсәтелгән[56]. Габделмөэмин хәзрәт Ташкичү авылында, 1890 елның 4 июлендә указ (номеры № 4179) алып[57], шактый күп еллар дәвамында имамлык вазыйфаларын башкарган. Халык сөйләвенә караганда, ул йөз-кыяфәте белән Ш. Мәрҗанигә бик охшаган булган. Кабере зиратның көньяк-көнчыгыш ягында.

[56] ТР Милли архивы: ф. 2, тасв. 2, сак. бер. 4033. – Б. 7.
[57] ТР Милли архивы: ф. 2, тасв. 2, сак. бер. 7100. – Б. 49 арты–50.

**20. Дамелла Габденнасыйр Мөхәммәдәмин улына куелган кабер ташы, 1886 ел.**

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Бу кабер сахибе надирел-әмсали
2) улан галим гамил Буаның дамелла Габденнасыйр
3) бине Мөхәммәдәмин гомер шәрифләрине нәшре голүм
4) диниййә вә ихйаи шәргый шәриф нәбәвиййә сарыф
5) идүб 70 йәшендә 1303 сәнәдә һиҗрилә
6) рәҗәбнең 6 нчы йәүмендә даре бәкайә сәфәр итдиләр».

Уң ягы (уеп язылган):
1) «Гыйбрәт ала ни ирүр гыйбрәте җиһан
2) китдиләр андин хисабсыз инсе җан
3) әнбийәи мөрсәлин андин нәкыль
4) кыйлдыйлар ал гыйбрәте әй зи гакыл
5) гамилә Габделбари әл-Казани».

Сул ягы (уеп язылган):
1) «Вә фиил-йәүмис-сәәдиси
2) мин раҗәбин вә бил-мәсиихиййәти сәнәтә 1886
3) таййибәллааһү дариихәһү вә җәгалә фиил-җәннәти
4) раухәһ

5) вәдагать һәзәәл-хәҗәра ибнәтүһүл-кәриимәтү Зөһрә»[58].

Арткы ягы (уеп язылган):

1) «Һәзиһи раудатүл-гаалим-

2) –ил-кәәмилит-тәкыйййилләзии нәшшәра гыйльмәһү

3) фиил-әәфәәкый вә галәә фәдълиһи вә вәрагыйһи ингакад-

4) –әл-иттифәәка Әбиил-Һидәйәти Габденнасыйр

5) бине Мөхәммәдәмин әш-Шортый сүммә әл-Бувави

6) түвүффийә вә һүвә-бнү фии сәбгыыйнә сәнәтә 1303 бил-һиҗрийййәһ»[59].

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:

1) «Бу кабер иясе мисаллары сирәк

2) булган галим, гамәл кылучы Буадан дамелла Габденнасыйр

3) бине Мөхәммәдәмин, гомер шәрифләрен дини гыйлем

4) тарату һәм пәйгамбәр шәригать шәрифен торгызуга сарыф

5) итеп, 70 яшендә һиҗри белән 1303 ел

6) рәҗәбенең 6 нчы көнендә мәңгелек дөньяга сәфәргә киттеләр».

---

[58] Башы арткы ягында.

[59] Дәвамы сул ягында.

Уң ягы:

1) «Гыйбрәт ала, нәрсә булыр ул җиһан гыйбрәте?
2) Киттеләр аннан хисапсыз кеше җаннары.
3) Пәйгамбәрләр, илчеләр аннан
4) күченделәр – ал гыйбрәт, әй, акыл иясе.
5) Габделбари Казани язды».

Сул ягы:

1) «алтынчы
2) рәҗәбендә, милади 1886 елда [вафат].
3) Аллаһ аның каберен яхшы итсен һәм урынын
4) җәннәт итсен.
5) Бу ташны кадерле кызы Зөһрә куйды».

Арткы ягы:

1) «Бу – галим,
2) камил, Аллаһтан куркучы, тирә-якка үзенең гыйлмен
3) тараткан һәм аның кадере, диндарлыгы бергә
4) җыелган Әбел-Һидәят Габденнасыйр
5) бине Мөхәммәдәмин Шортый Буави бакчасы.
6) 70 яшендә һижри 1303 елда вафат».

*Китапның кушымтадагы фотосын кара: б. 68, №№ 20, 20а.*

Таш үлчәмнәре: 100х50х47.

Әлеге кабер иясе – Ш. Мәрҗани хатыны Бибизөһрәнең газиз атасы.

Аның шәҗәрәсе түбәндәгечә: Габденнасыйр бине Мөхәммәдәмин бине Җәгъфәр бине Яфис. Габденнасыйр хәзрәт чыгышы белән хәзерге Чувашия Республикасы Татар Шорты авылыннан булса кирәк. Ни өчендер Мәрҗани аның 73 яшендә бакыйлыкка күчкәнен язып калдырган[60].

Ш. Мәрҗани әлеге бабасы, ягъни дүртенче хатынының атасы хакында болай язган: Халык белән аралашуы аз иде, дан һәм кадер-хөрмәт күрү белән гомер кичерде, тарафларында булган галимнәрнең мәшһүрләреннән иде»[61].

Ахырдан әйтәсе килгән сүзебез шул: барлык ташъязма истәлекләребезне кулдан килгәнчә саклап калырга тырышыйк, ягъни үлгәннәрнең каберен белик, борынгы кабер ташларының кадерен белик!

---

[60] Мәрҗани Ш.Б. Әл-кыйсмес-сани мин мөстәфадел-әхбари фи әхвали Казан вә Болгар. – Казан: Казан университеты тәбгыханәсе, 1900. – Б. 283.

[61] Шунда ук. – Б. 283.

## Эпиграфик истәлекләрнең фоторәсемнәре



№ 1



№ 1а



№ 1ә



№ 1б



**№ 2**




**№ 3**



**№ 3а**



**№ 5**



**№ 4**



**№ 4a**



**№ 6**



**№ 6a**


№ 7


№ 8


№ 9


№ 9а



**№ 10**



**№ 13**



**№ 11**




**№ 11а**



**№ 12**



**№ 12a**



**№ 15**



**№ 15a**




**№ 14**



**№ 17**



**№ 16**



**№ 16a**



**№ 18**



**№ 19**



**№ 20**



**№ 20а**

# КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ


1. Баруди Г. Хәдис: Гыйлемсез галим, төш мәсьәләсе, зиярәте кобур хәдисе. Хатыннарның кабергә зиярәтләре. Әдәбе зиярәт / Г. Баруди // Дин вә әдәб. – 1913. – № 24. – Б. 740–746.

2. Гыйбадәт кылулар һәм дини йолалар уздыру турында Нигезләмә. – Казан: Хузур, 1436/2014. – 48 б.

3. Марджани Ш. Зрелая мудрость в разъяснении догматов ан-Насафи (ал-Хикма ал-балига) / Шигабутдин Марджани; предисл. и пер. с араб. Д. Шагавиева. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2008. – 479 с.

4. Мәрҗани (Русия мөселманнарының бөек галимнәреннән) // Шура. – 1914. – № 10. – Б. 289–291.

5. Мәрҗани: фәнни-популяр җыентык. – Казан: Җыен, 2010. – 704 б.

6. Мәрҗани Ш. Әл-бәркыйль-вәмидъ галәл-бәгыйдыйль-мөсәмма бин-нәкыйдъ / Ш. Мәрҗани. – Казан: Вячеслав типографиясе, 1888. – 65 б.

7. Мәрҗани Ш.Б. Әл-кыйсмес-сани мин мөстәфадел-әхбари фи әхвали Казан вә Болгар. – Казан: Казан университеты тәбгыханәсе, 1900. – 368 б.

8. Мәрҗани Ш.Б. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – 415 б.

9. Мәрҗани: Шиһабеддин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең вәлядәтенә йөз ел тулу (1233–1333) мөнәсәбәтилә нәшер ителде. – Казан: «Мәгариф» матбагасы: Нашире Салих бине Сабит Гобәйдуллин, 1333 (1915). – 193 б.

10. Мәрхүм мулла Борһанетдин Мәрҗани // Кояш. – 1916. – 4 март. – Б. 2.

11. Татарстан Республикасының Милли архивы.

12. Тәрҗемани К. Борһанетдин Мәрҗани хәзрәт / К. Тәрҗемани // Кояш. – 1916. – 6 март. – Б. 2–3.

13. Тукай Г. Актык тамчы яшь: шигырьләр / Г. Тукай; төз. һәм кереш сүз авт. Л. Шәех. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. – 495 б.

14. Фәхреддинев Р.С. Болгар вә Казан төрекләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. – 287 б.

15. Фәхреддин Ризаэддин. Асар. 2 том. – Казан: Рухият, 2009. – 304 б.

16. Шәрәф Б. Мәрҗани хакында җавапларым / Б. Шәрәф // Шура. – 1911. – № 24. – Б. 757–759.

17. Шихабутдин Марджани: сборник статей, посвященный 100-летию Ш. Марджани, изданный в Казани в 1915 г. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2015. – 494 с.

18. Юсупов М.Х. Шигабутдин Марджани как историк / М.Х. Юсупов. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1981. – 232 с.

# ЭЧТӘЛЕК

**Шиһабетдин хәзрәт һәм кабер ташлары** ..........................3

**Мәрҗани һәм аның туганнарының ташбилгеләре** .......13

Казан шәһәренең Яңа татар бистәсе зираты .................13

Арча районы Байкал (Яңа Тазлар) авылы зираты ........36

Арча районы Иске Ашыт авылы зираты .......................39

Арча районы Кысна авылы зираты ................................44

Арча районы Ташкичү авылы зираты ..........................47

Буа шәһәре зираты .........................................................57

Кушымта.
**Эпиграфик истәлекләрнең фоторәсемнәре** ...............61

Кулланылган әдәбият ...........................................................69

***Гайнутдинов Айдар Марсилевич***

**Эпиграфические памятники,**
**связанные с Марджани**

*(на татарском языке)*

*Научное издание*

Оригинал-макет – *Л.М. Зигангареева*
Подписано в печать 4.09.2018 г.  Формат 60×84 $^{1}/_{16}$
Усл. печ. листов 4,5  Тираж 200 экз.

Отпечатано с готового оригинал-макета

ИЗДАТЕЛЬСКИЙ ДОМ
им. академика В.И. Андреева

420108, г. Казань, ул. Портовая, 25а
Тел./факс: (843) 231-05-46,
231-08-71, 231-04-19
E-mail: citlogos@mail.ru
www.logos-press.ru

Сайт
Института истории
Академии наук РТ
Татаровед.рф